СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
№ 2-16

Карар
22 июнь 2022ел.

Албай авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Албай авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советының 2021 елның 22 ноябрендәге 1-12 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмә»не үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган «Мамадыш муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү турында нигезләмә»не үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /И.П. Крешков/

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛБАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001355